**СОВЕТ НОВОШЕШМИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ ЯҢА ЧИШМӘ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы,423190

тел.: (8-84348) 2-20-08, факс: (8-84348) 2-21-73, Nsmsp.Nsm@tatar.ru

**Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Яңа Чишмә авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

**2017 елның "06" июленнән** **№ 20-70**

**«Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Яңа Чишмә авыл җирлеге советының 2014 елның 21 ноябрендәге 33-102 номерлы карары белән расланган «Яңа Чишмә авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында» Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында»**

Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексына үзгәрешләр кертү хакында 2016 елның 26 декабрендәге 107-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Яңа Чишмә авыл җирлеге Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының 2014 елның 21 ноябрендәге 33-102 номерлы карары белән расланган «Яңа Чишмә авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында» Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә

**3.6 статьяның 1 өлешендәге 3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:**

«3) шәхсән яисә ышанычлы затлар аша эшкуарлык эшчәнлеге белән шөгыльләнергә, коммерция оешмасы идарәсендә яисә коммерциягә карамаган оешма идарәсендә (сәяси партия идарәсендә катнашудан тыш); башка иҗтимагый оешманың, торак, торак, торак-төзелеш, гараж кооперативларынын, бакчачылык, яшелчәчелек, дача кулланучылар кооперативларының, күчемсез мөлкәт милекчеләре ширкәтләренең съездында (конференциясендә) яисә гомуми җыелышында катнашуга; бер кеше башкара торган башкарма орган буларак (сәяси партиядән тыш) идарә итүдә яисә аларның коллегиаль идарә органнары составына керүенә түләүсез нигездә, яллаучы (эш бирүче) вәкиленең муниципаль хокукый актта билгеләнгән тәртиптә рөхсәте белән) федераль законнарда каралган очраклардан һәм оешма идарәсендә катнашу җирле үзидарә органы исеменнән Россия Федерациясе законнары нигезендә гамәлгә ашырыла торган очраклардан тыш;

**5.2 статьяның 3 һәм 4 пунктын яңа редакциядә укырга**

3.Муниципаль хезмәт вазыйфаларының барлык төркемнәре буенча ел саен төп түләүле отпуск 30 календарь көн күләмендә билгеләнде

4. Ел саен өстәмә түләүле отпуск муниципаль хезмәткәргә тиешле еллар эшләгән өчен, шулай ук федераль законнарда, Татарстан Республикасы законнарында һәм әлеге нигезләмәдә каралган очракларда бирелә. Тиешле еллар эшләгән өчен муниципаль хезмәткәргә еллык өстәмә түләүле отпускның дәвамлылыгы муниципаль хезмәтнең һәр елы, 10 календарь көн дәвамлылыгы өчен бер календарь көн исәбеннән исәпләнә.

**5.2 статьяның 4 пунктына түбәндәге эчтәлекле 41 өлеш өстәргә:**

«41. Нормалаштырылмаган хезмәт көне билгеләнгән муниципаль хезмәткәргә нормалаштырылмаган хезмәт көне дәвамлылыгы өч календарь көнгә тигез еллык өстәмә түләүле отпуск бирелә.

2. Әлеге Федераль закон үз көченә кергән көнгә файдаланылмаган еллык түләүле отпусклар яисә шушы отпускларның бер өлеше булган муниципаль хезмәткәрләр өчен алардан файдалану хокукын, шулай ук файдаланылмаган еллык түләүле отпусклар яисә шушы отпускларның өлешләре өчен акчалата компенсация түләүне саклап калырга.

3. Әлеге карарны 5.2 статьясы таләпләре нигезендә, яңа хезмәт елыннан башлап, әлеге Федераль закон үз көченә кергән көнгә муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүче муниципаль хезмәткәргә бирелә торган еллык түләүле отпускларның дәвамлылыгын исәпләргә.

4. Әлеге карарны Яңа Чишмә муниципаль районы Яңа Чишмә авыл җирлегенең рәсми сайтында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы адресы буенча урнашкан авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында: Татарстан Республикасы, Яңа Чишмә районы, Ленин урамы, 44 йорт, 48а йорт адресы буенча урнашкан мәгълүмат стендларында игълан итәргә (бастырырга).

**Яңа Чишмә муниципаль районы**
**Яңа Чишмә авыл җирлеге Башлыгы** **В.М. Козлов**